ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Тел./факс: (85556) 2-57-52, e-mail: landysh.sayfullina@tatar.ru, http://muslumovo.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.01.2021 г. Мөслим № 13

Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче
гражданнарның аерым категорияләренә
торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен
түләү буенча социаль ярдәм чаралары
турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары (2009 елның 16 июлендәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарның түбәндәге категорияләренә Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән торакның социаль нормасы һәм коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары чикләрендә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының 100% күләмендә социаль ярдәм чараларын билгеләргә:

торак, җылылык, ут өчен түләү – педагогик хезмәткәрләргә, белем бирү оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәдәният өлкәсе хезмәткәрләренә. Социаль ярдәмнең күрсәтелгән чарасы, әгәр алар авыл җирлегендә урнашкан мәгариф учреждениеләрендә, мәдәният һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә 10 елдан да ким эшләмәсәләр һәм шунда яшәсәләр, пенсиягә чыккан хезмәткәрләргә дә сакланып кала.

Социаль ярдәм чаралары алучы гражданнарның салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча түләнергә тиешле бурычы булмаска тиеш.

2.«Адреслылык принцибын саклау һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чы гып социаль яклау чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе нең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче учреждениеләргә социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат бирүне социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – ЕГИСО) куллану аша социаль ярдәм чаралары турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, ЕГИСО операторы билгеләгән форматларга туры китереп тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.А.Ильясов**